РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина,15

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КУКМАРА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 17 марта 2022 ел №15

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль зиратларында Хәрби Дан Аллеяларында күмү Тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында күмүү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Кукмара поселок Советының 2010 елның 16 апрелендәге 7 нче карары белән расланган Кукмара шәһәр тибындагы поселогы территориясендә ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту турындагы Нигезләмә нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль зиратларында Хәрби Дан Аллеяларында җирләү Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

**Җитәкче вазифаларын башкаручы** **Р. Р. Хәйруллин**

Исполнительный комитет города Кукмор ИНН 1623008296 Кукмара шәһәре башкарма комитеты

Татарстан Республикасы Кукмара
муниципаль районы Кукмара шәһәре
Башкарма комитетының 2022 елның «17»
марта 15 номерлы карарына кушымта

# Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль зиратларында Хәрби Дан Аллеяларында җирләү Тәртибе

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль зиратларында Хәрби Дан Аллеяларында күмү тәртибе (алга таба – Тәртип) үлгәннәрне күмүгә бәйле мөнәсәбәтләрне җайга сала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендә урнашкан зиратларда Хәрби Дан Аллеяларында күмү хокукы булган вафат булганнарның (һәлак булганнарның) категорияләрен билгели һәм Хәрби Дан Аллеяларында вафат булганнарны (һәлак булганнарны) күмүгә ризалык бирү турында карарлар кабул итү тәртибен билгели.

1.2. Әлеге Тәртип максатларында түбәндәге төшенчәләр һәм терминнар кулланыла:

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендә урнашкан зиратларда Хәрби Дан Аллеясы (алга таба – Хәрби Дан Аллеясы) – Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендә булган гамәлдәге зиратлар чикләрендә урнашкан, зиратларның генераль планында яисә схемасында каралган, исән вакытта әлеге Тәртипнең 2.1 пунктларында күрсәтелгән затлар булган вафат булган (һәлак булган) гражданнарның гәүдәләрен (мәетләрен) күмү өчен билгеләнгән җир кишәрлеге.

## 2. Хәрби Дан Аллеяларында күмелергә мөмкин булган гражданнар категорияләре.

2.1. Әлеге Тәртип нигезендә Хәрби Дан Аллеясында гомер иткәндә түбәндәгеләргә ия булган һәм /яки үлгәннән соң бүләкләнгән вафат булганнар (һәлак булганнар) күмелергә мөмкин:

- Советлар Союзы һәм Россия Федерациясе Геройлары;
- «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен», «Кызыл Йолдыз», «Изге Георгий», «Ватан алдындагы казанышлар өчен», «Суворов», «Ушаков», «Жуков», «Кутузов», «Нахимов», «Батырлык», «Хәрби казанышлар өчен», «Диңгездәге казанышлар өчен» орденнары белән бүләкләнгән гражданнар;
- Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидлары;
- сугыш хәрәкәтләре ветераннары һәм инвалидлары;
- хәрби хезмәт ветераннары;
- дәүләт мәнфәгатьләрен, шулай ук гражданнарның намусын һәм абруен яклаганда батырлык һәм каһарманлык күрсәтеп һәлак булган (вафат булган) хәрби хезмәткәрләр һәм законда хәрби хезмәт, эчке эшләр, Дәүләт янгынга каршы хезмәт органнарында, җинаять-башкарма системасы учреждениеләрендә һәм органнарында, Россия Федерациясенең мәҗбүри үтәтү органнарында хезмәт каралган федераль башкарма хакимият органнары (федераль дәүләт органнары) хезмәткәрләре.

хезмәт каралган федераль башкарма хакимият органнары (федераль дәүләт органнары) хезмәткәрләре.

2.2. Хәрби Дан Аллеясында күмү, әгәр дә бу вафат булган (һәлак булган) кешенең исән вакыттагы ихтыярына яисә аның хатынының, якын туганнарының, башка туганнарының яки вафат булган (һәлак булган) кешене күмүне үз өстенә алган затларның теләкләренә каршы килмәсә мөмкин.

2.3. Хәрби Дан Аллеясында бер үк кабергә җирләү (күмү) рөхсәт ителми.

## 3. Вафат булган (һәлак булган) кешене Хәрби Дан Аллеяларында күмүгә ризалык бирү турында карарлар кабул итү тәртибе

3.1. Хәрби Дан Аллеяларында җирләү өчен җир кишәрлекләре Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитетының зиратлар администраторлары (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан ритуаль хезмәтләр оештыру һәм Кукмара шәһәр тибындагы поселогы территориясендә күмү урыннарын карап тоту турындагы Кукмара поселогы Советының 2010 елның 16 апрелендәге 7 номерлы карары белән расланган Нигезләмәнең (алга таба – Нигезләмә) 5 бүлеге нигезендә бирелә.

3.2. Хәрби Дан Аллеяларында вафат булган (һәлак булган) кешенең гәүдәсен (мәетен) күмүгә ризалык бирү турындагы карар Башкарма комитет тарафыннан кабул ителә.

3.3. Гамәлдәге законнар нигезендә вафат булган (һәлак булган) кешенең гәүдәсен (мәетен) күмү бурычын үз өстенә алган зат (алга таба – гариза бирүче), вафат булган (һәлак булган) кешене Хәрби Дан Аллеясында күмүгә ризалык алу өчен, Нигезләмәнең 5 бүлегендә каралган документлар белән беррәттән, Башкарма комитетка түбәндәге документларны тапшыра:

3.3.1. вафат булган (һәлак булган) кешене әлеге Тәртип нигезендә Хәрби Дан Аллеясында күмүгә ризалык бирү турында Башкарма комитет җитәкчесе исеменә гариза;

3.3.2. вафат булган (һәлак булган) кешенең әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында санап үтелгән гражданнар категориясенә керүен раслый торган документлар күчермәләре;

3.3.3. ышанычнамә күчермәсе, документларны гариза бирүченең вәкиле тапшырган очракта.

Югарыда күрсәтелгән документларны кабул иткәндә, Башкарма комитетның җаваплы хезмәткәре тапшырылган документларның күчермәләрен аларның төп нөсхәләре белән чагыштыра.

3.4. Тапшырылган документлар гариза бирүчедән (яисә аның вәкиленнән) документлар кергән мизгелдән ике эш көненнән дә артмаган вакыт эчендә Башкарма комитет тарафыннан карала, ул гариза бирүчегә яисә аның законлы вәкиленә Хәрби Дан Аллеясында вафат булган (һәлак булган) кешене күмүгә ризалык бирү яки вафат булган (һәлак булган) кешене Хәрби Дан Аллеясында күмүгә ризалык бирүдән баш тарту турында Башкарма комитет карары формасында Карар кабул итә.

3.5. Гариза бирүчегә яки аның вәкиленә вафат булган (һәлак булган) кешене Хәрби Дан аллеясында күмүгә ризалык бирүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

3.5.1. әлеге Тәртипнең 3.3 пунктларында каралган документларның тулы булмаган исемлеген бирү;

3.5.2. әлеге Тәртипнең 2.1 һәм 2.2 пунктларында билгеләнгән таләпләрне үтәмәү.

3.6. Гариза бирүче һәм (яки) аның вәкиле әлеге Тәртипнең 3.4 пунктында күрсәтелгән Башкарма комитет карары белән танышырга һәм әлеге карарның күчермәләрен алырга хокуклы.

3.7. Башкарма комитетның һәм (яки) аның хезмәткәрләренең әлеге Тәртип белән бәйле карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) гамәлдәге законнарда һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актларында каралган тәртиптә һәм шартларда шикаять бирелергә мөмкин.